**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 22 май № 295

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 663 нче; 2006 ел, 2 май, 216 нчы; 2008 ел, 27 июнь, 449 нчы; 2009 ел, 13 июль, 491 нче; 2010 ел, 11 июнь, 465 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1035 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 29 август, 724 нче; 2011 ел, 29 август, 726 нчы; 2012 ел, 8 сентябрь, 761 нче; 2013 ел, 19 март, 190 нчы; 2014 ел, 1 февраль, 54 нче; 2014 ел,11 март, 150 нче; 2014 ел, 16 май, 325 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1042 нче; 2015 ел, 30 июнь, 472 нче; 2016 ел, 13 май, 301 нче; 2016 ел, 22 октябрь, 769 нчы; 2016 ел, 30 ноябрь, 880 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктның 3.3.2 пунктчасында:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмә һәм Спорт судьялары турында нигезләмә нигезендә «спорт мастерына кандидат», «беренче спорт разряды» спорт разрядларын һәм «беренче категориядәге спорт судьясы» спорт судьясы квалификация категориясен бирү, алу, торгызу;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«милли спорт төрләре буенча спорт исемнәре һәм спорт разрядларын, аларны бирү өчен нормалар, таләпләр һәм шартлар эчтәлеген, шулай ук аларны бирү тәртибен билгеләү.»;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«россия допингка каршы оешмасы, физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе спорт җыелма командалары спортчыларын медик-биологик һәм медицина тәэминатына вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән берлектә спортта допингны булдырмау һәм аңа каршы көрәшү буенча эшне оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\295.docx